РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 55-0-43, факс 55-0-43

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**24.10.2022** **№ 3**

**2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегененең Кушкуй торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Нармонка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 15 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Көшкүй авылы, Ленин урамы, 26 йорт 2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Күшкүй Нармонка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2023 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Нармонка авыл җирлегенең Кушкуй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, бары тик көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем Инвалидларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәт итәргә чакырылган гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында торучы гражданнардан тыш махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, волонтерлар) һәм аларның гаилә әгъзалары: ата-аналары, хатыннары, балигъ булган балалары;

махсус хәрби операциядә катнашучылар (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, волонтерлар) һәлак булган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәргән:

- Кушкуй т. п. зират территориясен койма белән ремонтлау ( төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча хезмәтләр өчен түләү)?».

" КАРШЫ " "РИЗА"

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән

игълан итәргә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы .

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче урынбасары** **Н.С. Зотова**